ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail: ik.umr@tatar.ru, sovet.umr@tatar.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_10_»__10__2025 г. №1010

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының 15.07.2021 № 542 карары
белән расланган Муниципаль милектәге җирләрне һәм
(яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир
кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»гы 28.02.2022 елның 175 санлы карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының "Административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында"гы 22.05.2025 ел, № 1-31/8045 хатына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 15.07.2021 ел, № 542 карары белән расланган Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 3.5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.6.2-3.6.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.6.2 - 3.6.4 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

1.2. Регламентның 3.5.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.5. Регламент пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы 15 эш көне тәшкил итә, җир кишәрлеген яңадан бүлү турында хәбәр басылып чыккан очракта - 49 эш көне.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
т. 2-42-05